**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«15» 06 2026 ел Яр Чаллы ш. № 1959

«2026 елда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2025 елның 26 декабрендәге 4476 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары, «Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, «Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 елның 03 мартындагы 130 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына таяныпбалаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру,

балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатыннан

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2026 елда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 26 декабрендәге 4476 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2026 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы буенча балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне 3 кушымта нигезендә расларга.

1.2. 2026 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы буенча балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыру буенча ведомствоара комиссия составын 4 кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны 3 эш көне эчендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның «15» 06 1959 номерлы карарына 3 кушымта

**Тукай муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

1. Балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыру буенча ведомствоара комиссия (алга таба - Комиссия) Тукай муниципаль районы дәүләт хакимияте башкарма органнарының җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган учреждениеләр, балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыру өлкәсендәге оешмалар белән килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү максатында төзелгән вәкаләтле орган булып тора.

2. Комиссияне ике урынбасары булган рәис җитәкли. Комиссия рәисе аның эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Комиссия утырышларын алып бара, комиссиянең эш планын раслый. Комиссия рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Комиссия рәисе урынбасарларының берсе башкара.

Комиссия составына кызыксынган учреждениеләр, бүлекләр, ведомстволар һәм оешмалар вәкилләре керә. Комиссия составы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

3. Комиссия составына шулай ук Комиссия секретаре керә. Комиссия секретаре Комиссия утырышларын әзерләү эшен оештыра һәм Комиссия утырышларында кабул ителә торган карарларның үтәлешенә мониторинг үтәрә. Секретарь Комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча Комиссия рәисе һәм аның урынбасары йөкләмәләрен үти.

4. Комиссия үз эшчәнлегендә гамәлдәге федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

5. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

- балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген әзерләү һәм оештыру буенча муниципаль район учреждениеләре, бүлекләре, ведомстволары, предприятиеләр һәм барлык милек формасындагы берләшмәләр, иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген координацияләү;

- балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыру буенча муниципаль район учреждениеләре, бүлекләре, ведомстволары, оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләр эшчәнлегенә анализ ясау, Комиссия утырышларында аларның хисапларын тыңлау, үз вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

- балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген финанслау һәм оештыру мәсьәләләрен карау;

- балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген тәэмин итү программаларын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту;

- балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыру эшчәнлеге формалары һәм эчтәлеген камилләштерү;

- балаларның һәм яшьләрнең иҗади потенциалын үстерү, аларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, авыруларны профилактикалау, янгынга каршы, санитария-гигиена һәм эпидемия каршы таләпләрне үтәү, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;

- балалар һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү учреждениеләре челтәрен саклап калу һәм үстерү;

- сәламәтләндерү кампаниясе вакытында балаларның имгәнүен булдырмау.

6. Комиссия хокуклы:

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген тәэмин итү программаларын расларга, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыру чараларын гамәлгә ашыру турында төзелгән килешүләр кысаларында сменаларны оештыручыларны билгеләргә;

- балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына кертергә; балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыруда катнашучы бүлекләрдән, ведомстволардан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, оешмалардан аның компетенциясенә караган документлар, белешмәләр, материаллар соратып алырга;

- балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының карарлары үтәлешен контрольдә тотарга;

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының балалары һәм яшьләренең ялы программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

7. Комиссия эшенең төп формасы булып кирәк булган саен уздырыла торган утырышлар тора. Комиссия утырышында аның әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, Комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

8. Комиссиянең үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарлары барлык бүлекләр, ведомстволар, учреждениеләр, предприятиеләр һәм милек формаларына карамастан оешмалар тарафыннан үтәлүе мәҗбүри.

Комиссия үз эшчәнлеген аның утырышларында кабул ителә һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана торган эш планнары нигезендә гамәлгә ашыра.

9. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Утырышларның көн тәртибен һәм аларны үткәрү тәртибен Комиссия рәисе билгели. Утырышта әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип санала.

10. Комиссия карарлары утырышта катнашучы затларның гади күпчелек тавышы белән, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә, утырыш беркетмәләре белән рәсмиләштерелә һәм үтәлүе мәҗбүри булып тора. Утырыш беркетмәләре комиссия рәисе тарафыннан имзалана. Тавышлар саны тигез булганда, Комиссия рәисенең яисә аның урынбасарының тавышы хәлиткеч була.

11. Комиссия эшен оештыру-техник яктан тәэмин итү Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның «15» 06 1959 номерлы карарына 4 кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыру буенча ведомствоара комиссия составы**

| | | |
|---|---|---|
| | **Комиссия рәисе** | |
| 1 | Галиуллина А.С. | - Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| | **Рәис урынбасарлары** | |
| 2 | Гәрәев И.Р. | - Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы |
| 3 | Низамиева Э.Р. | - «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| | **Комиссия секретаре** | |
| 4 | Володин А.О. | - Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Балкыш» балаларсәламәтләндерү лагере» МБУ директоры |
| | **Комиссия әгъзалары** | |
| 5 | Хафизова Л.М. | - Татарстан Республикасында Роспотребнадзор территориаль идарәсенең Яр Чаллы шәһәрендәге, Актаныш, Тукай, Минзәлә районнарындагы территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| 6 | Әмирханова Р.Н. | - Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| 7 | Аверьянова О.Б. | - «Якты юл» район газетасының баш редакторы (килешү буенча) |
| 8 | Шакиров Л.М. | - Тукай муниципаль районында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | Әхмәтханов И.А. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча балигъ булмаганнар эшләре бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы (килешү буенча) |
| 10 | Лымарь Р.Р. | - «Тукай район үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| 11 | Хәкимова Э.В. | - Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча ДКУ департаментының гражданнарны кабул итү бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 12 | Мифтахов И.И. | - Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең Тукай муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 13 | Шәябтдинов А.А. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча полиция бүлеге башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча), полиция подполковнигы (килешү буенча) |
| 14 | Шәяхмәтова З.Г. | - Тукай муниципаль районы мәдәният бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 15 | Шакирова Н.Г. | - «Саулык» сәламәтләндерү-мәгариф комплексы идарәчесе («КамазЖИЛБЫТ» ҖЧЖ) (килешү буенча) |
| 16 | Хөснетдинова Г.Т. | - Тукай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре (килешү буенча) |
| 17 | Халикова А.Ф. | - Опека һәм попечительлек секторы мөдире (килешү буенча) |
| 18 | Низамиева А.Р. | - Башлык ярдәмчесе, «Беренчеләр Хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең Тукай муниципаль районы җирле бүлекчәсе рәисе |